ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 384 от «08» 11 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы башкарма комитетының
2018 елның 24 декабрендәге 607 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентларны яңа редакциядә раслау турында» 607 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Карарның 1 нче кушымтасының 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.1 пунктчасын өстәргә:

«коммерциячел булмаган оешмаларга мондый җир участокларында капиталь төзелеш объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү өчен әлеге капиталь төзелеш объектларын төзү һәм (яки) реконструкцияләү срогына»;

1.2 Карарның 5 нче кушымтасының 2.9 пунктындагы 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 Карарның 1 кушымтасының 39.6 статьясының 3 пунктындагы 2 пунктчасына «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

1.4 Карарның 1 нче кушымтасының 39.6 статьясындагы 2 пунктының 15 пунктчасындагы «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару» сүзләренә алмаштырырга;

0000011449

1.5 Карарның 1 нче кушымтасының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасында «бакчачылык» сүзеннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче О.Н.Павлов